**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М 146**
**28.03.2025**

«1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 80 ел» истәлек билгесе турында

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын билгеләп үтү йөзеннән, шәһәр Уставының 53 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 80 ел» истәлек билгесен гамәлгә кертергә.
2. «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 80 ел» истәлек билгесе турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.
3. Башкарма комитетка әлеге карарны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме                                        Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Хакименең
2025 елның 28 мартындагы
М 146 номерлы карарына
кушымта

«1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында
Җиңүгә 80 ел» истәлек билгесе турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 80 ел» истәлек билгесе (алга таба — Истәлек билгесе) Яр Чаллы шәһәрендә 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган тантаналы чараларда катнашучыларга һәм аларны оештыручыларга, шул исәптән 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветеран-катнашучыларына, махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарына, шулай ук Яр Чаллы шәһәре территориясендә эшчәнлек алып баручы, совет халкының 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган патриотик юнәлештәге чараларда катнашкан иҗтимагый оешмалар вәкилләренә тапшырыла.

Истәлек билгесе Яр Чаллы шәһәре бүләкләре системасына керми.

2. Истәлек билгесе тапшыруга тәкъдим ителә торган затларның беренчел исемлекләре, оешмалар/белем бирү оешмалары җитәкчеләренең әлеге Нигезләмәгә кушымтада каралган форма буенча Башкарма комитетка җибәрелә торган тәкъдимнәрен исәпкә алып, Башкарма комитетның структур бүлекчәләре, Башкарма комитетның районнар хакимиятләре тарафыннан төзелә. Истәлек билгесе тапшыруга тәкъдим ителгән затларның йомгаклау исемлеге Башкарма комитет тарафыннан формалаштырыла һәм раслау өчен шәһәр Хакименә җибәрелә.

3. Истәлек билгесен тапшыру Яр Чаллы шәһәре Хакиме, муниципаль берәмлек Башлыгы Урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе, Башкарма комитетның районнар хакимиятләре Башлыклары, шулай ук алар вәкаләт биргән вазыйфаи затлар тарафыннан 2025 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

4. «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 80 ел» истәлек билгесен һәм аңа таныклыклар әзерләү Башкарма комитет тарафыннан тәэмин ителә.

2 бүлек. Истәлек билгесенең тасвирламасы

5. Истәлек билгесе диаметры 32,6 мм, калынлыгы 3 мм (+/-0,5-1 мм) булган түгәрәк формасындагы сувенир медальдән (ике яклы) гыйбарәт. Аның өске өлешендә орден калодкасына беркетү өчен элмәк урнашкан. Медаль җиз металлдан эшләнгән, өслеге капланмаган.

Эшкәртелүе: шомартып ялтыратылган.

RAL буенча төсе -1004.

Истәлек билгесен әзерләү ысулы: ныклы корычтан эшләнгән индивидуаль клишелар кулланып, салкын юл белән чүкеп сурәт ясау.

Линияләрнең калынлыгы 0,1-0,2 мм булган 2D сурәт.

Истәлек билгесе орден колодкасына тоташтыру бөҗрасы белән беркетелә. Колодка ялтыравык тасма (Георгий тасмасы) белән тышланган. Ялтыравык эффектлы тасма, материал - вискоза җеп.

6. Билгенең график сурәте:




3 бүлек. Истәлек билгесе таныклыгының тасвирламасы

7. Истәлек билгесенә таныклык басып язылган, тыгызлыгы 250 грамм булган кәгазьдән эшләнгән.

Алгы ягында «ҖИҢҮГӘ 80 ЕЛ» логотибы. Язу: «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 80 ел» истәлек билгесенә ТАНЫКЛЫК». Эчке якта сулда Истәлек билгесенең сурәте.

Уң яктагы язулар: тутырылмаган Ф.И.А.и. графалары, алга таба язулар: «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 80 ел» истәлек билгесе белән БҮЛӘКЛӘНДЕ», астарак «Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиев», Хакимнең имзасы, мөһер урыны һәм бирү датасы.

Бөкләнгән килеш таныклыкның зурлыгы 82 мм (киңлеге) х 112 мм (биеклеге).

8. Таныклык макеты:






Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары — И.А. Сәгыйдуллина

«1941-1945 еллардагы
Бөек Ватан сугышында
Җиңүгә 80 ел» истәлек
билгесе турында нигезләмәгә
кушымта

Совет халкының 1941-1945 еллардагы
Бөек Ватан сугышында Җиңүнең
80 еллыгына багышланган тантаналы чараларда
(патриотик юнәлештәге чараларда) катнашкан
катнашучылар исемлеге

| № т/б | Ф.И.А.и. | Уку/эш урыны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Барлыгы: катнашучылар саны

Оешма җитәкчесе ____________________
Ф.И.А.и.

МУ